**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

Исполнительный комитет
Алькеевского сельского
поселения
Азнакаевского муниципального
района
Пер.Советский,44а,
423309 Тел. ( 885592) 37-4-23

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

Азнакай муниципаль районы
Әлкэй авыл жирлеге
комитеты

Пер.Советский, 44а
Әлкэй авылы, 423309
Тел. (885592) 37-4-23

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» сентябрь 2019 ел №34

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы «Әлкәй авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар чыгарам:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Әлкәй авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә,2 төркем инвалидларыннан бер тапкыр түләтүне 150 сумга киметеп үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Әлкәй авылында бәйрәмнәр уздыру “Җиңү көне”, “Сабантуй”, “Өлкәннәр көне”, “Яңа ел”,”Инвалидлар көне”;
- Әлкәй, Кызыл Сукачы авылларында янгын ранецлары сатып алу;
- Әлкәй, Кызыл Сукачы авыллары юлларын кардан чистарту;
- җәйге чорда Әлкәй, Кызыл Сукачы авылларында территорияләрне чабу;
- Әлкәй авылы Урак һәм Чүкеч урамы юлына вак таш (щебенка) җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү);
- Әлкәй, Кызыл Сукачы авылларында һәлак булган сугышчылар һәйкәлләрен төзекләндерү (чәчәк үсентеләре сатып алу);
- Әлкәй, Кызыл Сукачы авылларында эчәргә яраклы суга биохимик һәм бактериологик анализ үткәрү;
- Әлкәй, Кызыл Сукачы авылларында зиратларга дератизация уздыру.

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы, Әлкәй авылы, Пер.Совет ур.44а йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әлкәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык: С.З.Зиннурова